| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**14.01.2025** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 25** |

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 31 мартындагы 740 номерлы карары белән расланган, Муниципаль берәмлекләр мәгариф педагогик хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-техник яктан тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты Мәгариф идарәсе мәгълүмати-методик тәэмин итү бүлеге хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2024 елның 22 декабрендәге 1950/24 номерлы боерыгы нигезендә, «Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2022 елның 29 мартындагы 583/22 номерлы боерыгы белән расланган, Муниципаль берәмлекләрнең мәгариф өлкәсендәге педагогика хезмәткәрләре һөнәри квалификация төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-техник яктан тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге «исеме» Башкарма комитетының «Муниципаль район мәгариф идарәсе (бүлеге)» муниципаль казна учреждениесе составындагы мәгълүмати- методик яктан тәэмин итү бүлеге хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында типлаштырылган нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында», 2006 елның 22 февралендәге «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына мәгариф өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясындагы икенче өлешенә таянып, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 31 мартындагы 740 номерлы карары белән расланган, Муниципаль берәмлекләр мәгариф педагогик хезмәткәрләренең һөнәри

квалификация төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-техник яктан тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты Мәгариф идарәсе мәгълүмати-методик тәэмин итү бүлеге хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә (алга таба-Нигезләмә) ( 2024 елның 21 октябрендәге 3971 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 2 бүлегенең 1 пунктын, әлеге карарга кушымта нигезендә, яңа редакциядә бәян итәргә;

1.2. Нигезләмәнең «Стимуллаштыру характерындагы түләүләр» V бүлегенең 3.3 пунктындагы унынчы абзацында «Яшьлек һәм Һөнәри осталык» күкрәк тамгасы» сүзләрен өстәргә.

2. Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының (http://pravo.tatarstan.ru) рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) мәгълүмат сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарны 2025 елның 01 гыйнварыннан гамәлгә кертергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары - Мәгариф идарәсе башлыгы Р.В. Афанасьевага йөкләргә.

Җитәкче З.Ф.Хәбибуллин

Татарстан Республикасы Зеленодольск
муниципаль районы Башкарма комитетының
2025 елның 14 гыйнварындагы
25 номерлы карарына кушымта

1. Муниципаль берәмлекләрнең мәгариф бүлекләре (идарәләре) структурасындагы мәгълүмати-методик тәэмин итү бүлекләре хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазыйфа атамасы | Айлык база оклады күләме, сумнарда | | |
|---|---|---|---|---|
| | | төп гомуми белем, урта гомуми белем | квалификацияле эшчеләр (хезмәткәрләр) әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, урта звено белгечләрен әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, тулы булмаган югары белем | аттестацияне уңышлы үткән затка “бакалавр”, “магистр” яисә “дипломлы белгеч” бирү белән расланган югары һөнәри белем |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| Педагогик хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | | | |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | Методист | - | - | 20246,0 |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | Өлкән методист | - | - | 20251,0 |
| | | | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| Структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Муниципаль берәмлекләрнең мәгариф өлкәсендәге педагогик хезмәткәрләре һөнәри квалификация төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-техник яктан  тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы бүлекнең структур бүлекчәсе мөдире (башлыгы) урынбасары;<br>Муниципаль берәмлекләрнең мәгариф өлкәсендәге педагогик хезмәткәрләре һөнәри квалификация төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-техник яктан тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы бүлекнең структур бүлекчәсе мөдире (башлыгы) ; | - | - | 20329,0<br>20405,0 |